Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 19 декабре №10

Янил авыл җирлеге Советының 2024 елның 27 февралендәге 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Янил авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Янил авыл җирлеге Советының 2024 елның 27 февралендәге 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, Янил авыл җирлеге Советының 2024 елның 11 июнендәге 19 номерлы, 2024 елның 31 июлендәге 24 номерлы, 2024 елның 16 августындагы 28 номерлы, 2024 елның 04 декабрендәге 40 номерлы, 2025 елның 23 июнендәге 13 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып (алга таба – Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Унберенче төркем (халык саны 1,5 меңнән 5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 25 401,0 |

б) 3.1 пунктының беренче абзацында «15389» санын «16928» санына алыштырырга;

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Янил авыл
җирлеге башлыгы И.Х.Корбанов